ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Колхозная, дом 2,
село Матак, 422473
ИНН 1617003243

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТАК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Колхоз урамы, 2нче йорт,
Матак авылы, 422473

Тел.: (84375) 3-91-17, факс: (84375) 3-91-18, e-mail: Matak.Drz@tatar.ru.

с. Матаки

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 апрель 2019 ел № 6

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59 – ФЗ номерлы федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 нчы елның 8 нче февралендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге, җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.»;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге, җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына:

1.6.1 пунктта:

6.1 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 4 бүлегендәге очраклардан тыш, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап алырга, ә әлеге Регламентның 4.1 пунктындагы 8 пунктчасында каралган тәртиптә, аны бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәрнамә алырга;»;

2.сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

3. 7.5.6 пунктында "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, контроль, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимият федераль органының территориаль органы" сүзләрен «Эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимият федераль органының территориаль органы»сүзләренә алмаштырырга.

1. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Матак авыл җирлеге башлыгы: В.М.Михайлов